| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ<br>423737, Әтәс авылы,<br>Үзәк урам,<br>75 а йорты. Тел.5-90-25 | | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РУКОВОДИТЕЛЬ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>423737, село Атясево,<br>ул. Центральная, дом 75 а,<br>Тел. 5-90-25 |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабрь 2025 ел № 25

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Әтәс авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 һәм 28 статьяларына, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл җирлеге Уставына туры китереп, Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Әтәс авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлауларын 2026 елның 20 январенә билгеләргә.
2. Җәмәгать тыңлаулар үткәрү урыны итеп:
   - Апач авылында, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75а йорты адресы буенча урнашкан Әтәс авыл мәдәният йорты бинасы, үткәрү вакыты сәгать 8:00;
   - Әтәс авылында, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75а йорты адресы буенча урнашкан Әтәс авыл мәдәният йорты бинасы, үткәрү вакыты сәгать 10:00;
   - Чирү авылында, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75а йорты адресы буенча урнашкан Әтәс авыл мәдәният йорты бинасы, үткәрү вакыты сәгать 12:00;
   - Иске Бикчәнтәй авылында, Иске Бикчәнтәй авылы, Г.Тукай ур., 3 йорт адресы буенча урнашкан Иске Бикчәнтәй авыл клубы бинасы, үткәрү вакыты сәгать 14:00;
   - Чат авылында, Чат авылы, Үзәк ур., 43 йорт адресы буенча урнашкан Чат авыл клубы бинасы, үткәрү вакыты сәгать 16:00;
   - Чынык авылында, Чат авылы, Үзәк ур., 43 йорт адресы буенча урнашкан Чат авыл клубы бинасы, үткәрү вакыты сәгать 18:00;
3. Җәмәгать тыңлауларында каралачак мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм фикерләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Әтәс авылы, Үзәк урам, 75а йорты.
4. Бу карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат такталарында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча “Авыл җирлеге” бүлегендә бастырырга.
5. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Әтәс авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Э.Ф.Насыйрова